**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**06.08.2024 ел** **№37-07**

«Актаныш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 12-02 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына һәм Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 18 мартындагы 71-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Актаныш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 12-02 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.2 пунктта:**

«Энергетика нәтиҗәлелеген» сүзләреннән соң, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турындагы законнар» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 12 пунктны өстәргә:

«12) йорт эчендәге һәм (яисә) фатир эчендәге газ җиһазларын имин эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә карата таләпләр, шулай ук күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә караган вентиляция һәм төтен каналларын карап тоту таләпләре»;

**1.6 пунктта:**

«1-11» саннарын «1-12» саннарына алмаштырырга;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Совет рәисе Л.Р.Зарипов